СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 240 от 04.05.2018

на № ________ от ____________

# КАРАР

2018 елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мөлкәте булган муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 12 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мөлкәте булган муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.

2. Әлеге карарны (http://saby.tatarstan.ru) адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Саба муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 04.05.2018 ел 240 номерлы карары белән

2018 елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мөлкәте булган муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. 2018 елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы милкендә булган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның әлеге фараз планы (программасы) “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 12 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Саба муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру 2018 елның беренче яртыеллыгында муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыруга, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет кытлыгын каплау чыганакларын формалаштыруга юнәлдерелгән.

1.3. “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 12 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда яисә конкурста сату юлы яисә законда каралган башка чаралар белән, шулай ук Саба муниципаль районы устав капиталында 100% өлеше булган акционерлык җәмгыятенең устав капиталына кертү юлы белән башкару күзаллана.

1.4. 2018 елның беренче яртыеллыгында муниципаль мөлкәт булган муниципаль милек хосусыйлаштырыла.

1.5. 2018 елның беренче яртыеллыгында хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль күчемсез милек исемлеге 1 нче таблицада китерелә:

1нче таблица

| № п/п | Объектның исеме | Урнашкан урыны | Мәйданы, кв.м. | Хосусыйлаштыру срогы | Хосусыйлаштыру ысулы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | “Карлыгач” балалар бакчасы янәшә җир кишәрлеге белән (әлеге объект билгеләнеше буенча кулланылмый) | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Олы Нырты авылы, Х. Такташ урамы, 22Г йорт | 112,6 | 1 яртыеллык | Ачык аукционда сату юлы белән |
| 2 | Торак булмаган бина (әлеге объект | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, | 298,5 | 1 яртыеллык | устав капиталында Саба |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | билгеләнеше буенча кулланылмый) | Байлар Сабасы ш.т.б., Заводская урамы, 19 йорт, 1000нче бина | | | муниципаль районы өлеше 100% булган акционерлык җәмгыятенең устав капиталына кертү юлы белән |

1.6. 2018 елның беренче ярты еллыгында муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль милектәге акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

1.7. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру, шул исәптән мондый милекне сатып алучы затка читләштерү юлы белән сатылган мөлкәт, мондый мөлкәт биләгән һәм аларны куллануга кирәк булган җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында карар, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

2 бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү .

2.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында мәгълүматны тиз арада җиткерү өчен һәм рекламаны киңрәк тәэмин итү өчен Саба муниципаль районы әлеге фараз планын үтәү барышында мәгълүмат җиткерүнең рәсми чыганакларыннан тыш, башка массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән дә файдаланырга хокуклы.